**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**

**Оштырма-Юмья авыл җирлеге Башлыгы**

**Карары**

**10 ноябрь, 2023 ел** **№ 7**

**«Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Югары Юмья авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 20 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Май урамы, 25а йорты адресында урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 20 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Май урамы, 25а йорты адресында урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. 2023 елның 20 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Май урамы, 25а йорты адресында урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

4. 2023 елның 20 ноябрендә 19 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Май урамы, 25а йорты адресында урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Югары Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срочлы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Юмья авылының Тимер юл, Май, Тау асты урамнарындагы юлларны төзү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, сууткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү).

- Югары Юмья авылының Май, Тау саты урамы күперләрен төзү, ремонтлау, карап тоту (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, сууткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү).

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Югары Юмья авылында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавлары, стволлары, кучергечләре, колонкалары, мотопомпалары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

«Югары Юмья авылында сууткәргеч системасын, су суырту манарасын, скважиналарны һәм башка инженерлык челтәрләрен ремонтлау, карап тоту һәм төзекләндерү (кул белән һәм экскаватор белән туфрак эшкәртү, торба үткәргеч салу, ремонтлау, су суырту манарасы өчен бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, насос сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);»

- Югары Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту (кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- урам яктырту җайланмасы (урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;

- Югары Юмья авылында традицион җирләү урыннарын (зиратны) карап тоту, ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү, җирләү йортын төзү, ремонтлау, чүп контейнерлары сатып алу, урнаштыру, моточапкычлар, бензопычкылар, генератор һәм инвентарь (көрәкләр, тырмалар, ломнар, баскычлар) сатып алу (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка массакүләм ял итү урыннары (авыл клубы) төзү, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү) һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүлү.

7. Оштырма-Юмья авыл башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

8. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

9. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: С.В. Тимофеев